Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение «Высокогорская средняя общеобразовательная школа №2
Высокогорского муниципального района Республики Татарстан»

«Утверждаю»
Директор МБОУ «Высокогорская СОШ№ №2
__________Ф.Ф. Абдрахманов

Приказ №187 от 25.08.2022 г.

«Согласовано»

Заместитель директора по УР
__________ Степанова Е.Н.

«25» 08 2022г.

«Рассмотрено»

Руководитель ШМО
__________ Вафина

Протокол № 1 от «23» 08 2022

РАБОЧАЯ ПРОГРАММА ПО ПРЕДМЕТУ
Родной (татарский) язык
за курс средней школы

С. Высокая Гора, 2022 год

**РУС ТЕЛЕНДӘ ГОМУМИ БЕЛЕ**

Рус телендә гомуми белем бирү
Федераль дәүләт белем бирү стандарт
чыгып, укучыларга белем һәм тәрбия би
Рус телендә гомуми белем бирү
бирү түбәндәге бурычларны хәл итүне

- укучыларда гражданлык һ
- татар халкына хас булган
- ана теле үзенчәлекләрен а
- укучыларда җәмгыяви я
камилләштерү;
- хезмәткә әзер булу, булача
- үз-үзеңдә оешканлык тәрб
- телне тамгалар системасы
- ана теле нормаларын сакл
- тел берәмлекләренә танып, аларны тикшерә, чагыштыра алу һәм аралашуда урынлы куллану күнекмәләрен камилләштерү;

- ана теленнән алган белем һәм күнекмәләрне укучыларның үз сөйләмендә куллана алуларына ирешү;
- текст белән эшләү, аннан кирәкле мәгълүматны сайлап ала белү һәм аны тиешенчә үзгәртә алу күнекмәләрен үстерү;
- дәресләрдә алган белемнәрне аралашуның төрле өлкәләрендә урынлы һәм дөрес итеп куллана белү;
- укучыларның орфографик һәм пунктуацион грамоталылыгын үстерү.

Күрсәтелгән бурычлар аралашу, лингвистик, этномәдәни һәм иҗтимагый-мәдәният өлкәсенә караган компетенцияләрне булдырганда һәм үстергәндә тормышка ашырыла.

Программа шәхеснең гомуми культурасын шәхси һәм танып белү сыйфатларын яки универсаль уку гамәлләрен үстерүне күзаллый.

## 1. “ТУГАН ТЕЛ (ТАТАР ТЕЛЕ)” УКЫТУДАН КӨТЕЛГӘН ПРЕДМЕТ НӘТИҖӘЛӘРЕ

Стандарт һәм укыту предметының үзенчәлекләре нигезендә планлаштырылган предмет нәтиҗәләре түбәндәгеләр:

- телнең тормышта, җәмгыятьтә, дәүләттә тоткан роле турында күзаллау булдыру; рус теле, ана теле, чит тел һәм чит әдәбиятны өйрәнү аркылы милли һәм бөтендөнья мәдәнияте кыйммәтләренә якынаю;
- уку процессында һәм сыйныфтан тыш чараларда төрле формаларда, төрле темаларга ирекле аралашу мөмкинлеген булдыру;
- татар теленә карата уңай мөнәсәбәт булдыру, ана телен яхшы белүнең кирәклеген аңлау, аны дөрес итеп куллануга омтылу;
- татар теленең Татарстан Республикасында дәүләт теле буларак практик әһәмиятенә төшенү;
- татар теле нормаларына ия булу (орфоэпик, лексик, грамматик, орфографик, пунктуацион) һәм сөйләм культурасы кагыйдәләрен саклап укыганда, тормышның төрле ситуацияләрендә, аларны аралашу максатыннан чыгып, дөрес файдалана белү; үз сөйләменеңнең сыйфатына игътибар бирү;
- грамоталы язуга, төп орфографик һәм пунктуацион осталыкка ия булу;
- фонетика, графика, лексика, морфемика, грамматика, орфография төшенчәләрен, алар турындагы кагыйдәләрне куллана белү һәм шулай ук телнең төп берәмлекләрен (аваз, хәреф, сүз, җөмлә, текст) табу, тану, чагыштыра белү осталыгына ия булу.

Шәхеснең телдән һәм язма сөйләмне камил дәрәҗәдә белүе, аның гомуми культура дәрәҗәсенең югары икәнлеге турында сөйли.

### Программаны гамәлгә ашырудан көтелгән нәтиҗәләр

Өлкән сыйныф укучыларының татар телен белү дәрәҗәсе түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

- телнең төп функцияләрен белү;
- “сөйләм ситуациясе”, “әдәби тел”, “тел нормалары” һ.б. шундый төшенчәләрне аңлау;
- тел берәмлекләренең һәм тел ярусларының үзара бәйләнеше һәм билгеләрен үзләштерү;
- татар әдәби теленең орфоэпик, лексик, грамматик, орфографик һәм пунктуацион нормаларын белү;
- иҗтимагый-мәдәни, фәнни, рәсми-эш һәм тормыш көнкүреш өлкәсенә караган сөйләм әдәбе нормаларын куллана белү;
- телдән һәм язма сөйләм формасына һәм эчтәлегенә бәя бирә белү;
- текстка лингвистик анализ ясау;
- халыкның теле, тарихы һәм мәдәниятенең үзара тыгыз бәйләнештә булуын аңлау.

Ана теле дәресендә алган белемнәрне куллана белү түбәндәгеләрдә чагылыш таба:

- текстны жанр үзенчәлекләрен истә тотып уку (танышу, өйрәнү һ.б.);
- төрле чыганаклардан кирәкле мәгълүматны таба белү (фәнни, белешмә, электрон (Интернет) ресурслар);
- төрле жанрларда һәм стильләрдә рәсми, фәнни һәм көндәлек тормышны чагылдырган текстларны монологик һәм диалогик формада язу;
- телдән һәм язма сөйләмдә татар әдәби теленең орфоэпик, лексик һәм грамматик нормаларын саклау;
- төрле аралашу мохитендә кулланырга яраклы сөйләм әдәбе нормаларын саклау;
- язуда татар әдәби теленең орфографик һәм пунктуацион нормаларын саклау;
- телдән сөйләмдә һәм язуда татар әдәби теленә хас булган сүз тәртибен саклау;
- татар теленнән рус теленә рус теленнән татар теленә жанры һәм стиле төрле булган текстларны (телдән һәм язма формада) тәрҗемә итә белү.

## 2. “ТУГАН ТЕЛ (ТАТАР ТЕЛЕ)” УКЫТУ ПРЕДМЕТЫНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

### *Аралашу компетенциясен булдыру һәм үстерү*

Сөйләм. Сөйләмдә аралашу өлкәләре һәм ситуацияләре. Сөйләм ситуацияләрен тәшкил итә торган берәмлекләр.

Тел һәм сөйләм. Тел берәмлекләрен сөйләмдә куллану. Язма һәм телдән сөйләм. Сөйләмнең төп берәмлекләре: сүз, җөмлә һәм текст.

Сөйләм эшчәнлеге. Сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрен (тыңлап аңлау, сөйләү, уку һәм язу) камилләштерү буенча эшне дәвам итү.

Аралашуның төрле даирәсенә караган монологик һәм диалогик сөйләү күнекмәләрен үстерү.

Аралашучының халәтенә һәм текстның төренә карап, аны төрлечә уку күнекмәләрен камилләштерү.

Тәкъдим ителгән текстны мәгълүмати әһәмияте ягыннан чыгып үзгәртү.

Төрле стиль һәм жанрга караган текстлар төзү күнекмәләрен үстерү.

Фәнни, рәсми эш, публицистик, сөйләм һәм матур әдәбият стильләре, аларның үзенчәлекләре турындагы белемнәрне камилләштерү.

Фәнни һәм рәсми аралашуның телдән һәм язма формаларын куллану. Доклад, реферат, тезис, бәяләмә, алу кәгазе, ышаныч кәгазе кебек төрле жанрдагы эш кәгазьләрен язу күнекмәләрен булдыру һәм камилләштерү.

Сөйләм әдәбе нормаларын һәм телдән сөйләм культурасын саклау.

### X сыйныф

Укылган әсәр яки каралган спектакльгә бәяләмә язу.

Сыйныф яки мәктәп тормышындагы берәр кызыклы вакыйгага турында газетага мәкалә язу.

Сыйныфташ дустыңа характеристика язу.

Вакытлы матбугатта чыккан берәр мәкалә турында, үз фикереңне белдереп, редакциягә хат язу.

Милли сәнгатебезнең әһәмитле казанышы турында сыйныфташлар алдында чыгыш ясау.

Илдә һәм дөньяда бара торган сәяси вакыйгалар турында хәбәрдар булуны күрсәтү максатыннан чыгып, сыйныф каршында чыгыш ясау.

Иҗади характердагы язма эшләр (изложение, сочинение) язу.

Төрле орфографик кагыйдәләргә карата диктантлар язу.

Төрле эш кәгазьләре (гариза, автобиография, белешмә, беркетмә, килешү кәгазе һ.б.) язу.

Фәнни-популяр стильдәге текстларны тәрҗемә итү.

Төрле темаларга диалоглар (полилоглар) төзү һәм аны сыйныфта уку (сөйләшү).

**11 нче сыйныф**

Фәнни доклад язарга өйрәнү.

Актуаль темага «түгәрәк өстәл янында» сөйләшү үткәрү.

Сыйныфта язган сочинениегә, бергәләп, анализ ясау.

Белем көне уңаеннан укытучылар һәм укучылар белән әңгәмә кору.

Конспектлар төзү, тезислар язу.

Телләр өйрәнү мәсьәләсенә багышланган пресс-конференция уздыру.

Татарстанда ике теллелек мәсьәләләренә багышланган иҗади язма эшләр (сочинениеләр һәм изложениеләр) башкару.

Төрле эш кәгазьләре (бәяләмә, игълан, беркетмә, акт һ.б.) язу.

Программада каралган әдәби әсәрләрне өйрәнгәннән соң, сочинениеләр язу.

Иҗтимагый-публицистик стильдәге текстларны тәрҗемә итү.

***Тел һәм лингвистик компетенцияне булдыру һәм үстерү***

Иҗтимагый күренеш һәм тамгалар системасы буларак тел. Аның төп функцияләре.

Тел белеме турында мәгълүмат. Аның башка фәннәр арасындагы урыны.

Телләрне классификацияләү. Төрки телләр. Төрки телләр арасында татар теле. Татар теле турында гомуми мәгълүмат.

Татар әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше.

Татар һәм рус телләрендәге фонетик, лексик, грамматик аермалыклар һәм охшаш билгеләр.

Тел нормалары һәм сөйләмдә аларны урынлы файдалану. Аларның төп төрләре: татар әдәби теленең орфоэпик, лексик, стилистик һәм грамматик нормалары.

Орфоэпик нормалар. Телдән сөйләмдә орфоэпиянең роле. Әдәби әйтелешнең төп нормалары.

Лексик нормалар. Сүзләрне лексик мәгънәсен истә тотып, урынлы куллану – сөйләмнең мөһим шарты.

Граммматик нормалар. Сүз формаларын татар әдәби теле нормаларына туры китереп куллану. Җөмләләрдәге тиешле сүз тәртибен саклау, ия белән хәбәрне дөрес урынга кую.

Орфографик нормалар. Татар орфографиясе бүлекләре һәм дөрес язу принциплары.

Пунктуацион нормалар. Татар телендә тыныш билгеләре һәм аларны дөрес кую кагыйдәләре.

Хәзерге татар әдәби теленең сүзлекләре һәм белешмәләре: орфографик, аңлатмалы, орфоэпик, тәрҗемәи сүзлекләр һәм төрле белешмәләр, аларны көндәлек тормышта куллану күнекмәләрен үстерү.

Орфографик һәм пунктуацион белем һәм күнекмәләрне камилләштерү.

Тел берәмлекләренең һәм ярусларының үзара бәйләнеше. Татар телендә синонимия күренеше.

Татар теленнән рус теленә, рус теленнән татар теленә тәрҗемә итү.

Төрле жанрда язылган текстларга лингвистик анализ ясау.

Туры һәм кыек сөйләм.
Пунктуация.
Стилистика һәм сөйләм культурасы. Татар әдәби теленең функциональ стильләре.

## X сыйныф

**Тел – аралашу чарасы.** Телнең төп функцияләре. Шәхесне формалаштыруда ана теленең роле.
Төрки телләр арасында татар теле. Татар теле турында гомуми мәгълүмат.
**Татар теле белеменең төп бүлекләре.**
Фонетика. Орфоэпия. Графика. Сузык һәм тартык авазларның сөйләмдә үзгәрүе. Сүз басымы. Интонация.
**Лексикология.**
Сүзләрнең лексик мәгънәсе. Бер һәм күпмәгънәле сүзләр.
Сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре. Фразеологизмнар. Лексикография.
**Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы.**
Татар теленең сүз төзелеше үзенчәлекләре. Сүз ясалышы ысуллары.
**Сөйләм үстерү.**

## XI сыйныф

**Грамматика.**
Грамматика турында гомуми төшенчә. Грамматиканың бүлекләре.
**Морфология.**
Татар теленең сүз төркемнәре. Сүзләргә морфологик анализ ясау.
**Синтаксис.**
Төп синтаксик берәмлекләр: сүз, сүзтезмә һәм җөмлә. Гади һәм катлаулы җөмлә синтаксисы.
Текст. Текст турында төшенчә, аның төп билгеләре.
Текстның темасы, идеясе һәм микротемасы.
Туры һәм кыек сөйләм.
Гади һәм кушма җөмләләргә синтаксик анализ ясау.
**Стилистика һәм сөйләм культурасы.**
Татар әдәби теленең функциональ стильләре.
**Сөйләм үстерү.**

## X - XI сыйныфларны тәмамлаучы укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр

***“Фонетик, орфоэпия һәм графика”*** бүлеге буенча

**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнә:**

- сүзләргә фонетик анализ ясый;
- сөйләмдә татар теленең орфоэпик нормаларын саклый;
- татар теленең орфоэпик сүзлегеннән, белешмә әдәбияттан кирәкле мәгълүматны сайлап ала һәм аларны төрле сөйләм ситуацияләрендә куллана.

**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнү мөмкинлеген ала:**

- сәнгатьле уку чараларын тану;
- төрле жанрлардагы текстларны сәнгатьле итеп уку;
- татар теленең орфоэпик сүзлегеннән, белешмә әдәбияттан кирәкле мәгълүматны мультимедия формасында алу һәм аларны төрле сөйләм ситуацияләрендә куллану.

***"Лексикология"*** бүлеге буенча

**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнә:**

- мәгънәсе, килеп чыгышы, куллану активлыгы һәм өлкәсе буенча сүзгә лексик анализ ясый;
- сүзләрне тематик төркемнәргә берләштерә;
- бәйләнешле сөйләмгә ирешү максатыннан урынсыз кабатлауларны булдырмый;
- метафора һәм эпитетларны аера;
- аңлатмалы, фразеологик, синонимнар һәм антонимнар сүзлекләрен куллана.

**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнү мөмкинлеген ала:**

- татар теленең лексик составын классификацияләү;
- сүзләрнең лексик һәм грамматик аермалыкларын билгеләү;
- төрле сүзлекләрдән һәм мультимедия чараларыннан кирәкле мәгълүматны аерып чыгару;
- үзенең һәм чит кеше сөйләмендәге сүзләренең мәгънә аермалыкларын билгеләү;
- төрле жанрлардагы (публицистик һәм әдәби, фәнни-рәсми) тектлардагы лексик-фразеологик чаралардан файдалану.

***"Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы"*** бүлеге буенча

**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнә:**

- сүзләрнең төзелешен тикшерә;
- сүз ясалышы ысуларын билгели һәм мисаллар китерә;
- укытучы тәкъдим иткән сүзләрдән тамырдаш сүзләр ясый;
- сүзнең морфема төзелеше буенча сүз төркемнәрен һәм җөмлә кисәкләрен таный.

**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнү мөмкинлеген ала:**

- тамырдаш сүзләр арасында семантик бәйләнеш булдыру;
- белешмә әдәбияттан кирәкле мәгълүматны мультимедия формасында алу һәм аларны төрле сөйләм ситуацияләрендә куллану;
- сүзнең орфографик һәм лексик мәгънәсен үзләштерү максатыннан чыгып, аның этимологиясен ачыклау.

*“Морфология”* бүлеге буенча

**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнә:**

- сүз төркемнәрен тикшерә;
- хәзерге татар әдәби теле кысаларында төрле сүз төркемнәрен файдалана;
- орфографик нормаларны үти һәм анализ ясау өчен, морфологиядән алган белемннәрне файдалана.

**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнү мөмкинлеген ала:**

- грамматик омонимнарны аеру;
- публицистик һәм әдәби, фәнни һәм рәсми эш стильләрендә сүз төркемнәренең төрле формаларын файдалану;
- төрле сүзлекләрдән, белешмә әдәбияттан һәм мультимедия чараларыннан морфология буенча кирәкле мәгълүматны табу һәм аларны төрле сөйләм ситуацияләрендә куллану.

*“Синтаксис”* бүлеге буенча

**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнә:**

- сүзтезмәләрне һәм җөмләләрне җөмләдә кулланылу мөмкинлекләреннән чыгып анализлый;
- хәзерге татар әдәби теле кысаларында, сүз төркемнәренең синтаксик формаларын аера;
- төрле анализлар ясаганда, синтаксистан алган белем һәм күнекмәләрне файдалана.

**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнү мөмкинлеген ала:**

- төрле жанрдагы текстларда синтаксик чараларны файдалану;
- функциональ-стилистик үзенчәлекләрненнән чыгып, синтаксик анализ ясау.

*“Орфография һәм пунктуация”* бүлеге буенча

**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнә:**

- программа кысалары нигезендә орфография һәм пунктуация нормаларын куллана;
- аерым сүзләрнең телдән һәм язма аңлатмаларын әйтә;
- орфография һәм пунктуация хаталарын аера һәм төзәтә.

**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнү мөмкинлеген ала:**

- телдән һәм язма сөйләмдә орфография һәм пунктуация нормаларын саклауның әһәмиятлелеген һәм кирәклеген аңлау;
- төрле сүзлекләрдән (аңлатмалы, синонимнар, антонимнар, чит тел сүзләре, фразеологик) һәм мультимедия чараларыннан сөйләмдә дөрес куллану өчен кирәкле мәгълүматны алу.

*“Стилистика”* бүлеге буенча

**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнә:**

- фәнни, рәсми эш һәм публицистик стильләрне һәм аларның жанр үзенчәлекләрен билгели;
- иптәшләре каршында (аудиториядә) чыгыш ясау үзенчәлеген ачыклый: тематикасын билгели, максатын һәм бурычларын ачыклый;

- чыгышына материалны укучыларның яшь һәм психологик үзенчәлекләрен, аларның белем, осталык һәм күнекмәләре дәрәҗәсен истә тотып кертә.

**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнү мөмкинлеген ала:**

- телдән һәм язма сөйләмнең үзенчәлеген аеру;
- төрле жанрдагы һәм стильләге текстлар (әзер текстларны уку, яки куелган бурыч һәм максатлар буенча аны үзгәртү) белән эшләү;
- телдән һәм язма сөйләм нормаларын саклап, төрле жанрдагы һәм стильләге текстларны рус теленнән татар теленә һәм татар теленнән рус теленә тәрҗемә итү.

***“Тел һәм мәдәният”*** бүлеге буенча

**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнә:**

- халык авыз иҗаты әсәрләреннән, тарихи романнардан һ.б. этнокультура компоненты булган лингвистик берәмлекләрне аера;
- телне өйрәнү илнең тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүгә ярдәм итә дигән фикерне исбатлау өчен, әдәби әсәрләрдән мисаллар таба;
- көндәлек тормышта урынлы куллану өчен, татар сөйләм әдәбе кагыйдәләрен өйрәнә (уку процессында һәм сыйныфтан тыш эшләрдә).

**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнү мөмкинлеген ала:**

- телнең халык мәдәнияте һәм тарихы белән тыгыз бәйләнештә яшәвен өйрәнелгән фәннәр үрнәгендә тасвирлау;
- татар сөйләм әдәбен Россиядәге башка милләтләрнеке белән чагыштыру күнекмәләрен булдыру.

***Этномәдәни һәм иҗтимагый-мәдәни компетенция***

Тел белән мәдәниятнең үзара бәйләнеше.

Татар көнкүрешенә караган лексика: тарихи сүзләр, халык авыз иҗатына караган сүзләр һәм фразеологизмнар; татар исемнәре. Мәкаль һәм әйтемнәр.

Татар телендә татар, рус һәм башка халкыларның матди һәм рухи мәдәнияте чагылышы. Рус һәм башка телләрдән татар теленә күчкән сүзләр.

Сүзлек составының милли мәдәниятләрнең үзара тәэсир итешүе нәтиҗәсе буларак баюы.

Татар теленең төрле милләтләр мәдәнияте белән бәйләнеше.

Татар теленә рус һәм Европа телләреннән кергән сүзләр. Милли телләрнең бер-берсенә тәэсир итү нәтиҗәсе буларак алынмалар.

Татар сөйләм әдәбенә караган сүзләр, аларның лексик-грамматик үзенчәлекләре.

Иҗтимагый-мәдәни компетенция түбәндәге осталыкларны булдыруны күзаллый:

- ❖ өйрәнелә торган телнең мәдәни нормаларын һәм традицияләрен белү;
- ❖ иҗтимагый-мәдәни шартларга туры килгән уңайлы аралашу стилен сайлау;
- ❖ иҗтимагый-мәдәни эчтәлектәге ыгы-зыгыларны булдырмау һәм, килеп чыккан очракта, аларны уңай хәл итә белү;
- ❖ җәмгыятьтә, гаиләдә һәм эштә шәхеснең үз урынын белүе;
- ❖ өйрәнгән телдә аралашканда, сабырлык, түземлелек күрсәтү һәм әңгәмәдәшкә ихтирамлы булу һ.б.

## 3. “ТУГАН ТЕЛ (ТАТАР ТЕЛЕ)” УКЫТУ ПРЕДМЕТЫНЫҢ

## ТЕМАТИК ПЛАНЫ

| Программаның төп темалары | Сәгать саны | Уку эшчәнлегенең төп төрләре |
|---|---|---|
| **10 нчы сыйныф** | | |
| **V–IX сыйныфларда үткәннәрне кабатлау** | **3** | V–IX сыйныфларда өйрәнгән материалны телдән һәм язма сөйләмдә дөрес куллану. |
| **Тел – аралашу чарасы.** Телнең төп функцияләре. Шәхесне формалаштыруда ана теленең роле. | **3** | Кеше тормышында телнең иҗтимагый әһәмиятен аңлау. Телне халыкара аралашу чарасы итеп кабул итү. Аның иҗтимагый тормышта һәм һәрбер кешенең тормышындагы ролен аңлау.<br>Яшь буынга ана теленең мөһимлеген аңлату. |
| **Төрки телләр**. Төрки телләр арасында татар теле. Татар теле турында гомуми мәгълүмат. Татар һәм рус телләренең үзара мөнәсәбәте. | **3** | Дөньядагы телләр арасында төрки телләр турындагы белемнәрне камилләштерү. Төрки телләр арасында татар теленең урынын аңлау. Татар әдәби теленең формалашу һәм үсү тарихы турында гомуми мәгълүмат алу. Рус теле – башка милләт вәкилләре белән аралашу коралы. |
| **Татар теле белеменең төп бүлекләре.**<br>Фонетика. Орфоэпия. Графика. Сузык һәм тартык авазларның сөйләмдә үзгәрүе. Сүз басымы. Интонация. | **6** | Хәзерге әдәби тел бүлекләре турындагы белемнәрне системага салу һәм актуальләштерү. Дөрес әйтелеш күнекмәләрен камилләштерү, басымны һәм интонацияне саклау. Татар теленең аваз һәм график системасы турындагы белемнәрне системага салу. Аваз белән хәрефнең туры килмәү очраклары күзәтелгән сүзләргә фонетик анализ ясау. |
| **Лексикология.**<br>Сүзләрнең лексик мәгънәсе. Бер һәм күпмәгънәле сүзләр.<br>Сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре. Фразеологизмнар. Лексикография. | **5** | Укучыларның сүз байлыгын арттыру. Югары сыйныфлар өйрәнә торган лексик берәмлекләрне белү.<br>Сөйләмдә фразеологизмнарны, күп мәгънәле сүзләрне, омонимнарны, синонимнарны, антонимнарны аеру һәм куллану. Туры һәм күчерелмә мәгънәле сүзләрне билгели белү. Сүзлекләрнең төрләре, аларны төзү принциплары. Сүзләргә лексик анализ ясау. |
| **Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы.** | **9** | Татар сүзләренең төзелеш үзенчәлекләрен таный белү |

| | | |
|---|---|---|
| Татар теленең сүз төзелеше үзенчәлекләре. Сүз ясалышы ысуллары. | | (тамыр, нигез, кушымчалар). Сүз төркемнәренең төрле ысуллар ярдәмендә ясалышын билгеләү һәм куллану. Төрле сүз төркемнәрен төзелеше һәм ясалышы буенча тикшерү. |
| **Сөйләм үстерү.** | **6** | Үз фикереңне белдерү, аны нигезләү. Татар телен начаррак белүче яшьтәшләр һәм өлкәннәр белән аралашканда, татар сөйләм әдәбе үзенчәлекләрен саклау. |
| **Барлыгы:** | **35** | |
| **11 нче сыйныф** | | |
| **Кабатлау.** | **2** | |
| **Грамматика.**<br>Грамматика турында гомуми төшенчә. Грамматиканың бүлекләре. | **2** | Укучыларны грамматиканың төп терминнары белән таныштыру: грамматик мәгънә, грамматик форма һәм грамматик категория. Хәзерге татар әдәби теле грамматикасының үзенчәлекләре турында белемнәрне камилләштерү. |
| **Морфология.**<br>Татар теленең сүз төркемнәре. Морфологик анализ. | **9** | Татар теле морфологиясеннән алган белемнәрне системага салу: сүз төркемнәренең төрләре, аларның исемләшүе. Телдән һәм язма сөйләмдә төрле сүз төркемнәрен урынлы итеп куллану. Мөстәкыйль, бәйләгеч һәм модаль мәгънәле сүз төркемнәре турында өйрәнгәннәрне системага салу, аларны телдән һәм язмача аралашканда тиешенчә куллану һәм морфологик анализ ясау. |
| **Синтаксис.**<br>Төп синтаксик берәмлекләр: сүз, сүзтезмә һәм җөмлә. Гади һәм катлаулы җөмлә синтаксисы. | **9** | Синтаксистан алган белемнәрне системага салу: төп синтаксик берәмлекләр, җөмләдә сүзләр бәйләнешенең үзенчәлекләре һәм төрләре. Гади җөмлә төрләре турында белемнәрне камилләштерү. Телдән һәм язма сөйләмдә сүз тәртибен саклау. Катлаулы җөмләләрнең үзенчәлекләрен өйрәнү (баш һәм иярчен җөмләләр арасында синтетик һәм аналитик бәйләнеш). Төрле җөмләләргә синтаксик анализ ясау. |
| **Текст.**<br>Текст турында төшенчә, аның төп билгеләре. | **5** | Телнең синтаксик берәмлеге буларак текст төшенчәсе белән танышу. Аның төп билгеләрен күрсәтү; тәкъдим |

| | | |
|---|---|---|
| Туры һәм кыек сөйләм. | | ителгән текстның темасын, идеясен әйтү; текстны микротемаларга аеру; бирелгән микротемалардан текст төзү. Тыңлаган һәм язма тексттан кызыл юлны билгеләү.<br>Укыган (тыңлаган) текст буенча план төзү. Ишеткән яки язма текстны темасы, идеясе һәм төзелеше буенча тикшерү. Текст төзегәндә тишле нормаларга таяну (темага туры килүе, мәгънәле кисәкләрнең эзлеклелеге һәм бәйләнеше). Үзең төзегән текстны һәм иптәшләреңнекен бәяләү һәм төзәтү.<br>Туры һәм кыек сөйләм турындагы белемнәрне системага салу. Аларны файдаланып, телдән һәм язма сөйләм оештыру. Туры һәм кыек сөйләмдә тыныш билгеләрен кую очракларын истә калдыру. Туры сөйләмне кыек сөйләмгә, кыек сөйләмне туры сөйләмгә әйләндерү. |
| **Сөйләм үстерү.** | **7** | Текст өстендә эшләү: аңа исем бирү, планын төзү. Тәкъдим ителгән темалар яки план буенча текстлар төзү. Фәнни темага чыгышлар ясау; аннотация, рефератлар язу. |
| **Барлыгы:** | **34** | |

**ЯЗМА ЭШЛӘРНЕҢ ЯКЫНЧА САНЫ**

| Эш төрләре | 10 нчы сыйныф | 11 нче сыйныф |
|---|---|---|
| Диктант | 4 (2)[1] | 4 (2) |
| Изложение | 4 (2) | 4 (2) |

[1]Җәяләр эчендә контроль язма эшләрнең саны күрсәтелә.

| | | |
|---|---|---|
| Сочинение | 2 (1) | 2 (1) |
| **Барлыгы** | **10 (5)** | **10 (5)** |

**Гомуми урта (тулы) белем бирү оешмасын тәмамлаучы**
**укучыларның белем, осталык һәм күнекмәләренә төп таләпләр**

**Тел бүлекләре буенча таләпләр**

***Фонетика һәм орфоэпия буенча:***

1. Татар телендәге сузык һәм тартык авазларның акустик-артикуляцион үзгәрешләрен белү. Рәт, аңкау һәм ирен гармониясен белү. Авазларны дөрес әйтү.
2. Сүз басымын дөрес кую. Сөйләмдә дөрес интонация куллану.
3. Сүзләргә фонетик анализ ясау.
4. Аваз һәм хәреф төшенчәләрен аеру. Алфавитны белү.

***Лексикология буенча:***

1. Татар теленең сүз байлыгын барлау, аңа характеристика бирү.
2. Сүзләрнең һәм фразеологик әйтелмәләрнең лексик мәгънәләрен аңлату, аларга синоним һәм антонимнар табу.
3. Аңлатмалы, энциклопедик, этимологик һәм тәрҗемә сүзлекләр белән эшләү.

***Стилистика буенча:***

1. Телебездә кулланыла торган стильләрне, аларның үзенчәлекләрен белү.
2. Төрле стильдәге текстларны аера белү. Стиль хаталарын төзәтү буенча эшләү.

***Сүз төзелеше һәм ясалышы буенча:***

1. Татар теленең ялганмалы табигатен аңлау. Сүзләрнең мәгънәле кисәкләрен (тамыр, нигез һәм кушымчаларны) билгеләү.
2. Сүзләрне төзелеше һәм ясалышы буенча тикшерү.

***Морфология буенча:***

1. Сүз төркемнәренең үзенчәлекләрен билгеләү, аларның лексик-грамматик, морфологик һәм синтаксик билгеләрен аңлау.
2. Өйрәнелгән сүз төркемнәренең морфологик билгеләрен күзаллау.
3. Сүз төркемнәренә морфологик анализ ясау.
4. Аларның төрле ысуллар белән ясалуын белү.

***Синтаксис һәм пунктуация буенча:***

1. Өйрәнә торган синтаксик берәмлекләрне аңлау.
2. Җөмләләрне сүзтезмәләргә таркату. Иярүче һәм ияртүче сүзләрне билгеләү, аларны бәйләүче тел чараларын табу.
3. Сүзтезмә белән җөмләнең бер-берсеннән аермасын белү.
4. Җөмләнең әйтү максаты буенча төрләрен, интонация һәм сүз тәртибен белү.
5. Гади җөмлә төрләрен билгеләү.
6. Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен табып, аларның кайсы сүз төркемнәре белән белдерелүен күрсәтү.
7. Гади һәм кушма җөмләләрне аера белү.
8. Җөмләдә тиңдәш кисәкләрне, кереш һәм эндәш сүзләрне табу.
9. Җөмләнең аерымланган кисәкләрен билгеләү.
10. Туры һәм кыек сөйләмнең үзенчәлекләрен аңлау.

11. Тыныш билгеләрен куюны аңлату.
12. Җөмлә ахырында, аерымлаган кисәкләр янында, тиңдәш кисәкләр, эндәш һәм кереш сүзләр янында тыныш билгеләре кую.
13. Ия белән хәбәр янында сызык кую очракларын белү.
14. Тезмә һәм иярченле кушма җөмләләрдә тыныш билгеләрен кую.
15. Диалог һәм туры сөйләм янында тыныш билгеләрен кую.

**Сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча таләпләр**

1. Телдән һәм язма сөйләм буенча:
   - репродуктив сөйләм: укылган яки тыңланган текстның эчтәлеген сөйләү яки язу;
   - продуктив сөйләм: бирелгән тема буенча тиешле әдәби нормаларга җавап бирә торган һәм эзлекле итеп оештырылган сөйләм.
2. Төрле стильдәге текстларны аңлы, йөгерек, дөрес һәм сәнгатьле итеп уку.
3. Төрле эш кәгазьләрен яза белү.
4. Караган фильмга яки спектакльгә, укылган китапка бәяләмә язу.
5. Төрле китапларга аннотация язу.
6. Программа буенча өйрәнелгән әдәби әсәр геройларына телдән яки язмача характеристика бирү.
7. Газета-журналларга мәкаләләр язу.
8. Тезислар, рефератлар һәм докладлар язу.